ҖОМГА
1
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 1 (6723)
Аерым номеры 15 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӘЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

31 нче декабрьда безнең гаскәрләр ОБЛИВСКАЯ шәһәрен һәм тимер юл станциясен һәм район үзәкләреннән НИЖНЕ-ЧИРСКАЯНЫ, ПРИЮТНОЕНЫ алдылар. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында самолетлар төялгән бер эшелон бар. Трофейларның исәбе алына.

ҮЗӘК фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерәләр.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Сталинградка килү юлларында безнең гаскәрләрнең 6 атналык һөҗүменең йомгаклары

1942 нче елның сентябрь урталарына таба Кызыл Армия немец-фашист гаскәрләрне Сталинград янында туктатты.

Сугышның барышы немецлар командованиесенең Сталинградны алудан, Советлар Союзының үзәк Европа өлешен Волга һәм Урал тылыннан аерудан, Москваны чолгап алудан һәм кулга төшерүдән гыйбарәт булган стратегик планының, үзләренең реаль көчләрен һәм советларның резервларын исәпкә алмыйча, комга корылганлыгын күрсәтте.

Сталинград янында немец-фашист гаскәрләрне чолгап алу һәм тар-мар итү буенча Кызыл Армиянең верховный баш командованиесе тарафыннан төзелгән стратегик план немецлар планының бөтенләй капма-каршысы булды.

Безнең гаскәрләр бу планны 1942 нче елның ноябрь-декабрь айларында өч этапка бүлеп тормышка ашырдылар.

I.

Беренче этап—Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләрнең һөҗүме

19 нчы ноябрьдан башлап Кызыл Армия Көньяк-Көнбатыш, Дон һәм Сталинград фронтларындагы көчләр белән һөҗүмгә күчте һәм дошманга куәтле удар ясады.

Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак хәрәкәт иткән совет гаскәрләре алдына Кызыл Армиянең верховный баш командованиесе Сталинградка килү юлларында немец-фашист гаскәрләрнең фланг группировкаларын тар-мар итү һәм дошман армиясенең Сталинград янында урнашкан берләшмәләренең төп массасын әйләнеп үтү юлы белән чолгап алу максатын куйган иде. Кызыл Армия частьларының һәм аның команда составының оста хәрәкәтләре белән бу максатка уңышлы рәвештә ирешелде.

Һөҗүм барышында безнең гаскәрләр дошманның түбәндә әйтелгән берләшмәләрен тар-мар иттеләр: румыннарның 1 нче, 2 нче, 5 нче, 6 нчы, 9 нчы, 13 нче, 14 нче, 15 нче пехота дивизияләре, румыннарның 7 нче һәм 8 нче кавалерия һәм 2 нче танк дивизияләре, немецларның 44 нче, 376 нчы, 384 нче пехота һәм 22 нче танк дивизияләре. Шуның өстенә немецларның 3 пехота дивизиясе авыр югалтуларга дучар ителде. Бу сугышларда безнең гаскәрләр дошманның 95.000 солдат һәм офицерын юк иттеләр һәм 72.400 кешене плен алдылар. Безнең частьлар бик күп трофейлар кулга төшерделәр, шулар арасында—134 самолет, 1.792 танк, 2.232 орудие, 7.306 автомашина, шулай ук бик күп санда минометлар, пулеметлар, автоматлар, танкка каршы ата торган мылтыклар, сугыш припаслары һәм башка төрле сугыш милекләре бар.

Шул ук вакыт эчендә безнең гаскәрләр дошманның 826 самолетын, 548 танкысын, 934 орудиесен, 3.190 автомашинасын һәм күп кенә башка төрле сугыш милекләрен юк иттеләр.

Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләрнең һөҗүме вакытында Кызыл Армия 70—150 километр алга китте һәм халык яши торган 213 пунктны азат итте.

Сталинград районында безнең гаскәрләрнең фронтны уңышлы рәвештә өзүләре һәм һөҗүмнәре нәтиҗәсендә немец гаскәрләренең түбәндә әйтелгән берләшмәләре һәм частьлары чолгап алынды: немецларның 14 нче, 16 нчы һәм 24 нче танк дивизияләре, немецларның 3 нче, 29 нчы һәм 60 нчы моторлаштырылган дивизияләре, немецларның 71 нче, 76 нчы, 79 нчы, 94 нче, 100 нче, 113 нче, 297 нче, 295 нче, 305 нче, 371 нче, 389 нчы һәм румыннарның 20 нче пехота дивизияләре, румыннарның 1 нче кавалерия дивизиясе һәм Сталинград районында безнең гаскәрләрнең һөҗүме вакытында немецларның туздырылган 44 нче, 376 нчы, 384 нче пехота дивизияләренең калдыклары. Шуның өстенә немецларның баш командованиесе резервындагы 44 нче, 46 нчы һәм 61 нче артиллерия полклары, 12 нче, 25 нче, 37 нче, 104 нче зенит полклары, 53 нче миномет полкы, 50 нче, 162 нче, 294 нче, 336 нчы аерым сапер батальоннары чолгап алындылар.

Сталинградка килү юлларында совет гаскәрләре һөҗүменең беренче этабында булган сугышларның йомгаклары шундый.

II.

Икенче этап—Донның урта агымы районында безнең гаскәрләрнең һөҗүме

Сталинград янында немец-фашист гаскәрләрне чолгап алуны тәгәлләп, шуның белән верховный баш командование тарафыннан куелган бурычны уңышлы рәвештә үтәгән-

(Дәвамы 2 нче биттә).

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. КАЛИНИННЫҢ яңа ел рече

Кадерле иптәшләр!

Советлар Союзы гражданнары! Эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар! Колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар! Совет интеллигенциясе! Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты сугышчылары, командирлары һәм политработниклары! Партизаннар һәм партизанкалар! Вакытлыча немец-фашист оккупантлар тарафыннан басып алынган совет районнарында торучалар! Сезне килеп җиткән яңа ел белән котларга рөхсәт итегез!

Үткән ел, иптшәләр, Ватан сугышы фронтларында бик каты сугышлар елы булды. Немецларның үткән елны Москва янында һәм фронтның башка участокларында булган җиңелүләреннән соң Гитлер үзенең вассалларын—Италияне, Румынияне, Венгрияне һәм хәтта читтән тыш хәлдән тайган Финляндияне дә үзләренең барлык кешеләр резервларын немецлар командованиесе карамагына бирергә мәҗбүр итте, Германиянең үзендә алырга мөмкин булганнарның бөтенесен җыйды. Франциядән һәм оккупацияләнгән башка илләрдән оккупация гаскәрләре частьларын алды һәм шундый тупланган йодрык белән быел безнең армиябезгә үлем удары ясарга уйлады.

Мин немецлар армиясенең төп ударларының юнәлеше һәм аның командованиесенең планнары турында әйтеп тормыйм. Болар барысы да иптәш Сталинның 1942 нче елның 6 нчы ноябрендә Москва Советының тантаналы утырышында ясаган докладында бик яхшы әйтелгәннәр. Тик шуны гына әйтеп үтәм: немецлар командованиесенең планнары фашистлар армиясенең көче җитәрлек булып чыкмады. Сугышлар читтән тыш каты, ә кай чакларда авыр характерда булды. Кызыл Армия совет җирен нык торып саклады, дошманга хәлдән тайдырырлык ударлар ясады һәм гитлерчыларның мәкерле планнарын өзде.

Сугышның үткән елгы йомгаклары турында гомумән фикер йөрткәндә бик ышанып әйтергә мөмкин, бүгенге көнне сугыш хәле безнең өчен үткән елны бу вакытта булганга караганда күп дәрәҗәдә яхшырак. Безнең армиябез ул чагында да дошманга җитди ударлар ясаган иде.

Быел немецлар бөтен фронт буйлап һөҗүм итмәделәр, бәлки көньяк һәм көньяк-көнбатыш юнәлешләрдә генә һөҗүм иттеләр, шулай булса да немецлар командованиесе үз алдына куйган максатына ирешә алмады. Немецлар армиясе сугыш хәрәкәтләре барышында шундый югалтуларга дучар ителде ки, бу югалтулардан аның һөҗүм көче бетте.

(Ахыры 2 нче биттә).

Сталинградка килү юлларында безнең гаскәрләрнең 6 атналык һөҗүменең йомгаклары

(Дәвамы. Башы 1 нче биттә).

нән соң Кызыл Армия 16 нчы декабрьдан 30 ына кадәр Донның урта агымы районында дошманга яңа удар ясады.

Донның урта агымы районында һөҗүм иткән совет гаскәрләре алдына Кызыл Армиянең верховный баш командованиесе Новая Калитва — Монастырщина районында дошманның сборона фронтын өзү, Донның зур борылышында хәрәкәт иткән немец-фашист армияләренең тылына чыгу һәм Сталинград янында чолганып алынган дошман гаскәрләренең котылып чыгулары мөмкинлеген яки аларга читтән ярдәм күрсәтү мөмкинлеген бетерү максатын куйган иде.

Донның урта агымы районындагы һөҗүмнең бу максаты Кызыл Армия частьларының һәм команда составының оста хәрәкәтләре белән тулысынча тормышка ашырылды.

Донның урта агымы районында булган сугышлар вакытында Кызыл Армия 150—200 километр алга китте. Халык яши торган 1.246 пункт азат ителде. Һөҗүм барышында безнең гаскәрләр дошманның түбәндә әйтелгән берләшмәләрен тар-мар иттеләр: немецларның 62 нче, 294 нче, 298 нче, 306 нчы, 385 нче пехота дивизияләре, немецларның 11 нче танк дивизиясе; итальяннарның 3 нче «Ровенна» дивизиясе, 3 нче «Челере» дивизиясе, 5 нче «Кассерия» дивизиясе, 2 нче «Сфорцесско» дивизиясе, 9 нчы «Пасубио» дивизиясе, 52 нче «Торино» дивизиясе, кара күлмәклеләрнең 1 нче бригадасы, румыннарның 7 нче һәм 11 нче пехота дивизияләре. Шуның өстенә дошманның 4 дивизиясе зур югалтуларга дучар ителде. Бу сугышларда дошман гаскәрләре, үтерелгән хәлдә генә дә, 59.000 кешеләрен югалттылар; дошманның 60.050 солдаты һәм офицеры плен алынды. Безнең гаскәрләр бик күп трофейлар кулга төшерделәр, шулар арасында 368 самолет, 178 танк, 1.927 орудие, 7.414 автомашина, шулай ук бик күп санда минометлар, пулеметлар, автоматлар, танкка каршы ата торган мылтыклар, сугыш припаслары һәм башка төрле сугыш милекләре бар.

Шуның өстенә безнең гаскәрләр дошманның 117 самолетын, 172 танкысын, 268 орудиесен, 1.000 нән артык автомашинасын һәм күп кенә башка төрле сугыш милекләрен юк иттеләр.

Сталинградка килү юлларында совет гаскәрләре һөҗүменең икенче этабында булган сугышларның йомгаклары шундый.

III.

Өченче этап—Сталинградтан көньяктарак безнең гаскәрләрнең һөҗүме

Немецлар командованиесе үзенең гаскәрләрен Сталинград янында тупикка кертеп һәм аларны һәлакәт алдына куеп, Сталинград янында Кызыл Армия тарафыннан чолганып алынган үз гаскәрләрен бик тырышып азат итәргә маташып карады. Моның өчен дошман Котельниководан төньяктарак булган районта зур гаскәрләр группировкасы туплады һәм 12 нче декабрьда безнең частьларга каршы һөҗүм хәрәкәтләре башлады.

Сталинградтан көньяктарак хәрәкәт итүче совет гаскәрләре алдына Кызыл Армиянең верховный баш командованиесе тарафыннан дошман гаскәрләренең яңа удар группировкасын тар мар итү, немецларны көньякка таба алып ташлау һәм аларны үзләренең Сталинград янында чолганып алынган дивизияләренә юл ачуга булган соңгы мөмкинлекләреннән мәхрум итү максаты куелган иде.

Бу максат безнең гаскәрләрнең Сталинградтан көньяктарак булган һөҗүмнәренең өченче этабында тормышка ашырылды.

Сталинградтан көньяктарак булган районда һөҗүм вакытында безнең гаскәрләр 100—150 километр алга киттеләр һәм халык яши торган 130 дан артык пунктны азат иттеләр. 12 нче декабрьдан 30 ына кадәр булган сугышлар барышында безнең гаскәрләр немецларның 6 нчы, 17 нче һәм 23 нче танк дивизияләрен, 16 нчы моторлаштырылган дивизиясен һәм румыннарның 4 нче һәм 18 нче пехота дивизияләрен, 5 нче һәм 8 нче кавалерия дивизияләрен тар-мар иттеләр. Немец-фашист гаскәрләр, үтерелгән хәлдә генә дә, 21.000 кешеләрен югалттылар. Дошманның 5.200 солдат һәм офицеры плен алынды. Безнең гаскәрләр кулга төшергән бик күп трофейлар арасында 40 самолет, 94 танк, 292 орудие, 329 автомашина, шулай ук күп кенә башка төрле кораллар, авиация һәм танк милекләре бар.

Сугышлар барышында безнең гаскәрләр дошманның 306 самолетын, 467 танкысын, 257 орудиесен, 945 автомашинасын һәм күп кенә башка төрле сугыш милекләрен юк иттеләр.

Совет гаскәрләре һөҗүменең өченче этабында булган сугышларның йомгаклары шундый.

Сталинградка килү юлларында немец-фашист гаскәрләрне чолгап алу һәм тар-мар итү буенча Кызыл Армиянең верховный баш командованиесенең планы әнә шулай өч этапта тормышка ашырылды.

* * *

Сталинградка килү юлларында булган 6 атналык сугышлар барышында безнең гаскәрләр халык яши торган 1.589 пунктны немец-фашист басып алучылардан азат иттеләр. 1942 нче елның 19 нчы ноябреннан алып һөҗүм вакытында Кызыл Армия, Сталинград районында дошманның 22 дивизиясен тыгыз боҗра итеп чолгап алып, иң кыен операцияне кыска вакыт эчендә уңышлы рәвештә үткәрде. Кызыл Армия дошманның барлыгы 36 дивизиясен, шулардан 6 танк дивизиясен тар-мар итте һәм 7 дивизиясен авыр югалтуларга дучар итте. Бу вакыт эчендә немец-фашист гаскәрләрнең 175.000 солдат һәм офицерлары үтерелде; безнең гаскәрләр 137.650 дошман солдатын һәм офицерын плен алдылар. Безнең гаскәрләр 542 самолет, 2.064 танк, 4.451 орудие, 2.734 миномет, 8.161 пулемет, 15.954 автомат, танкка каршы ата торган 3.703 мылтык, 137.850 винтовка, 5 миллионнан артык снаряд, 50 миллионнан артык патрон, 2.120 вагон, 46 паровоз, сугыш припаслары, корал һәм азык саклана торган 434 склад, 15.049 автомашина, 15.783 ат, 3.228 мотоцикл һәм бик күп санда башка төрле сугыш милекләре кулга төшерделәр.

(Ахыры 4 нче биттә).

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. КАЛИНИННЫҢ яңа ел речесе

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Безнең гаскәрләрнең Севастопольне геройларча саклаулары нәтиҗәсендә немец-румын гаскәрләре берничә дистә дивизияләрен югалттылар. Сталинград фронтында гына да немецларның югалтулары йөз мәннәрчә үтерелгән һәм яраланган кешеләр белән санала. Немецлар һөҗүменең башка юнәлешләрендә дә аларның югалтулары бик зур. Быел үзләре үткән юлның һәрбер километры өчен немецлар үткән елгыга караганда шактый күб корбаннар бирделәр. Шул ук вакытта Кызыл Армия дошман гаскәрләренә җавап ударлары ясау өчен көчләр әзерләде. Болар бөтенесе бергә шуңа китерделәр ки, инициатива яңадан безнең командование кулына күчте һәм ул аңардан шунда ук тулысынча файдаланды.

Владикавказ (Орджоникидзе) янында немец частьларына ясалган ударлар, Сталинград районында безнең каршы һөҗүмебез, шуның барышында немецларга бик каты ударлар ясалган булу, Үзәк фронтта безнең гаскәрләрнең һөҗүме, ниһаять Донның урта агымы районында һәм Төньяк Кавказда җәелеп бара торган һөҗүм бөтен Совет—Германия фронтында хәлне безнең файдага үзгәртәләр.

Сталинград районында 19 нчы ноябрьдан, Үзәк фронтта 25 нче ноябрьдан һәм Донның урта агымы районында 16 нчы декабрьдан башланган безнең һөҗүм нәтиҗәсендә немецлар шундый югалтуларга дучар ителделәр ки, бу югалтулар фронтның башка участокларына да тәэсир итмичә кала алмыйлар.

Һөҗүм нәтиҗәсендә күп ун меңнәрчә пленныйлар алынды, фашистларның дистәләрчә дивизияләре тар-мар ителде, бик күп трофейлар: йөзләрчә самолетлар, меңнәрчә танклар, орудиеләр, минометлар, пулеметлар, автоматлар, автомашиналар, миллионнарча снарядлар, патроннар кулга төшерелде, бик күп сугыш припаслары һәм азык складлары кулга төшерелде.

Безнең частьлар халык яши торган 2.000 нән артык авыл пунктларын, район үзәкләрен һәм шәһәрләрне алдылар.

Иптәшләр, үткән ел турында сөйләгәндә Советлар Союзының бөтен халкы арасында патриотлык хисләренең үсүен, җәмәгатьчелекнең фронтка бик күп төрле формаларда актив булышлык итүенең үсүен әйтеп үтәргә кирәк.

Эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар, инженер-техниклар персоналы совет коралының сыйфатын өзлексез яхшырталар, әйберләрне эшкәртү процессын системалы рәвештә яхшырталар, хезмәт интенсивлыгын арттыралар. Бу безнең Кызыл Армиябезне, безнең Хәрби Диңгез Флотыбызны кораллар һәм сугыш припаслары белән тоткарсыз тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Быел колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар чәчүлекләрне киңәйтүгә, игеннәрне урып-җыюга һәм терлекчелекне үстерүгә күп акыл һәм хезмәт куйдылар. Колхозчы крестьяннарның тырышлыклары бушка китмәде—быел иген уңышы яхшы булды һәм вакытында урып-җыелды. Оборона фондына билгеләнгән участоклар аеруча мәхәббәт белән эшкәртелде. Бу участоклар армия өчен планнан тыш шактый күп ашлык һәм яшелчә бирделәр.

Соңгы вакытларда самолетлар һәм танклар колонналары төзелешенә, стихияле төстә акча җыю кампаниясе җәелеп китте. Колхозчылардан һәм колхозчы хатын-кызлардан иптәш Сталин исеменә меңнәрчә телеграммалар килә. Бу телеграммаларда алар самолетлар һәм танклар төзелеше өчен банк бүлекләренә акча кертүләре турында шатлык белән белдерәләр, дәүләткә өстәмә рәвештә ашлык, ит һәм башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары тапшыралар. Бөтен совет халкы югары патриотлык хисе белән чолганып алынган. Шунсы характерлы, милли республикалардагы һәм ерак өлкәләрдәге колхозчылар үзәк өлкәләрдән калышмаска тырышып кына калмыйлар, бәлки алар керткән взнос суммаларыннан еш кына арттырып та җибәрәләр.

Безнең колхозчы крестьяннарыбызның Совет властена чын күңелдән бирелгәнлегенең, юлбашчыбыз һәм полководецыбыз иптәш Сталинга карата мәхәббәтенең бу ачык демонстрациясе сугышның ел ярымы эчендә совет тылының какшамаганлыгына, бәлки тагын да ныгыганлыгына, немец юлбасарларга каршы көрәштә кардәш халыкларның тагын да тыгызрак тупланганлыкларына иң яхшы үрнәк булып хезмәт итә.

Академиклардан алып авыл укытучыларына кадәр безнең интеллигенциябез үзенең барлык белемен һәм көчен Ватан өчен бирә. Лабораторияләрдә, тикшерену институтларында, завод мастерскойларында, шахталарда һәм буровойларда, колхоз лабораторияләрендә һәм турыдан туры кырларда, һәркайда да бер максатка—дошманны җиңү эшенә үзеннән өлеш кертү максатына юнәлдерелгән итаж рухы аңкый.

Кыюлык белән әйтергә мөмкин, бөтен совет халкы, кечкенәләреннән алып зурларына кадәр барлык милләтләр Совет Социалистик Республиклар Союзы өчен, немец-фашистларын җиңү өчен тыгыз сафларда торып көрәш алып баралар.

Халыкның үзенең армиясенә булган мәхәббәте фронтка бер өзлексез бүләкләр агылып торуда күренә. Һәрбер гражданин, хәтта балалар да Кызыл Армия сугышчыларына карата үзләренең кайгыртучанлыкларын һәм игътибарларын нәрсә белән булса да күрсәтергә тырышалар.

Иптәшләр, 1942 нче иске ел бетте. Ул безнең халкыбыз алдында катлаулы һәм кыен бурычлар калдырды, ләкин шуның белән бергә, киләсе елга күңелле перспективалар да калдырды.

Безнен халкыбыз фронтка үзенең булышлыгын торган саен активрак күрсәтә, бу булышлыкны өзлексез арттыру өчен яңадан-яңа мөмкинлекләр таба.

Безнең армиябез илне нык торып саклауда сугыш тәҗрибәсе алып кына калмады, бәлки йөгәннән ычкынган дошманны бик ныгытып кыйнарга да өйрәнде.

Партизаннарга каршы исәпсез җәза экспедицияләре җибәрелүгә һәм партизаннарга теләктәшлек күрсәткән крестьяннарны рәхимсез җәзалауларга да карамастан, партизаннар хәрәкәте үсә һәм немец-фашист оккупантларга торган саен күбрәк ударлар ясый.

Немец фашистларына каршы көрәштә союзникларның роле һаман арта барыр дип уйларга нигезләр бар.

Бөтен халык, армия һәм флот безнең җиребездән немец басып алучыларны тизрәк куу теләге белән яналар. Шулай булгач бу бөек максатны үтәү өчен барлык көчебезне, белемебезне һәм тәҗрибәбезне бирик, халыклар юлбашчысы, армия һәм флот полководецы иптәш Сталин тирәсенә тагын да тыгызрак тупланыйк һәм—безнең халкыбызның җиңүе тәэмин ителер.

Яңа ел белән, иптәшләр!

ТЫЛ—ФРОНТКА



«Спартак» комбинатының алдынгы стахановчысы, комбинат күләмендәге комсомол комитеты члены һәм цех комсоргы Екатерина Павлова үзе көнлек нормаларын 200—300 процентка үтәү белән бергә яшьләрне героик хезмәткә туплый. Рәсемдә: иптәш Павлова эш вакытында.

К. Тахтеев фотосы.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ФОНДЫНА

БАЛТАЧ. (Телефон буенча). Яңа ел уңае белән «Берек» колхозы членнарының гомуми җыелышы булды. Җыелышта колхозның 1942 нче елгы эшләренә йомгак ясалды һәм героик Кызыл Армиябезгә тагын ничек итеп яхшырак булышу мәсьәләсе куелды.

Иң башлап колхозчы Минһаҗ иптәш Фәхретдинов сүз алды. Ул колхозчыларның үз хуҗалыкларындагы ашлык запасларыннан Кызыл Армия фондына ашлык бүләк итү турында тәкъдим кертте һәм үзе бу фондка 7 пот ашлык бирде.

Колхозчылар иптәш Фәхретдиновның тәкъдименә бердәм кушылдылар. Фронтовик хатыны иптәш Гаязова 11 пот, Галимуллин 9 пот, Газизов һәм Каюмова иптәшләр 8 әр пот ашлык бирделәр. Кызыл Армия фондына бу колхоздан бер көн эчендә генә дә 312 пот ашлык җыелды.

ЙӨКЛӘМӘНЕ ҮТӘП

Арча районының күп кенә колхозлары яңа елны дәүләткә ит тапшыру буенча 1943 нче елгы планны арттырып үтәп каршы алалар. Мәсәлән, «Венера» колхозы 1943 нче елда дәүләткә 1.988 килограмм ит тапшырырга тиеш иде. Колхоз бу йөкләмәне хәзер үк инде 118 процентка үтәде. Шулай ук «Спартак № 1» колхозы 1943 нче елгы заданиене 271 килограммга, «Красное знамя» колхозы 161 килограммга, «Ударник» колхозы, 48, «Полярная звезда» колхозы 61 һәм «Дружба № 2» колхозы 90 килограммга арттырып үтәделәр.

Район буенча 1943 нче елда дәүләткә ит тапшыру заданиесе 45 процентка үтәлде инде.

НУР ХӘЙРУЛЛИН.

ТЕЛӘЧЕ. (Телефон буенча). «Боевик», «Дружба», «Красная звезда» колхозлары дәүләт алдындагы 1942 нче елгы барлык йөкләмәләрне 100 процентка үтәделәр. Бу колхоз членнарыннан күп кенә иптәшләр дәүләткә ит тапшыру буенча 1943 нче елгы планны да тутырдылар инде.

«Красная звезда» колхозы (председателе иптәш Бобров) яңа ел бүләге итеп Кызыл Армия фондына 424 килограмм ит тапшырды. «Комбайн» һәм Төрекбаш колхозлары 1943 нче елгы план исәбенә дәүләткә ит тапшыра башладылар.

М. МЕДВЕДЕВ.

Казан фармзаводының фронт бригадасы фронт заказларын көн саен 150 процентка үтәп бара. Рәсемдә: бригада членнарыннан (сулдан уңга) Г. Ф. Тумашева, А. Авдеева, А. Батмонова, һәм Г. Һадиева иптәшләр.

К. Тахтеев фотосы.

Партизаннарга

Татарстанның хезмәт ияләре Украина партизаннарына яңа ел бүләкләре туплауны оештырдылар. Бүләкләр төялгән 3 вагон 31 нче декабрьда Казаннан озатылды. Вагоннарны партизаннар тарафыннан җибәрелгән махсус вәкилләр алып баралар. Бүләкләр арасында меңнәрчә комплект телогрейкалар, колакчын бүрекләр, киез итекләр, күн итекләр, ботинкалар, гимнастеркалар, чалбарлар, бельелар, мех жилетлар, җылы бияләйләр һәм башка әйберләр бар. Шулар өстенә 1.000 данә аптечка, күп кенә сәгать, кәтүк җебе, энә, атлан май, какланган ит, кондитер товарлары, кер сабыны, исле сабын, тәмәке һәм башка бүләкләр җибәрелде.

Узган ел яхшы эшләдек, быел отлично эшләрбез

Тимер юл транспорты—Кызыл Армиянең туганы. Кызыл Армиянең уңышы, тимер юл транспортының төгәл эшләвенә дә бәйләнгән. Казан тимер юлчылары моны яхшы аңлыйлар.

1942 нче елда тимер юл транспорты сугышчан төстә эшләде. Казан тимер юлының машинистлары бу елны поездларны башка елларга караганда күп тапкыр кызуырак йөрттеләр, тимер юл эшчеләре йөк төяү һәм бушату эшләрен тагын да тизрәк башкардылар.

Фронт таләп иткәнчә эшләү нәтиҗәсендә Казан тимер юлының күп кенә бүлекләре, узеллары, деполары планнарын айдан-айга үтәп баруга, ә кайбер предприятиеләре Бөтенсоюз социалистик ярышта җиңеп чыгуга һәм күчмә Кызыл Байрак алуга ирештеләр.

Казан тимер юлындагы барлык деполарның да локомотивларга урта ремонт ясау буенча еллык планны ноябрьда ук үтәп чыгулары—1942 нче елда аларның тагын да яхшырак эшләгәнлекләрен күрсәтә торган ачык факт.

Әгерҗе узелының вагон участогы (начальнигы иптәш Куприянов) аеруча яхшы эшләде. Участок 1 нче декабрьга барлык күрсәткечләр буенча еллык программаны төгәлләде. Вагоннарга капиталь ремонт буенча задание ике ярым тапкырга, урта ремонт буенча 6 процентка арттырылып үтәлде. Ел ахырына кадәр участокта планнан тыш өстәмә рәвештә 70 вагонга урта ремонт үткәрелде. Ярдәмче цехларда продукция эшләп чыгаруның үсүе нәтиҗәсендә участок 10 ай эчендә 947.000 сумлык дәүләт средствосына экономия ясады.

Юдино паровоз депосы коллективы ремонт буенча еллык планны срогыннан элек үтәп, ел ахырына кадәр планнан тыш өстәмә рәвештә уннарча локомотивларга ремонт ясады.

Тимер юлчылар барысы да бер теләк белән—явыз дошманны тизрәк тар-мар итү теләге белән яналар. Шуның өчен алар үзләренең эш темпларын көннән-көн арттыралар.

— Без 1942 нче елда яхшы эшләдек, ә яңа елда отлично эшләрбез,—диләр алар.

ТАНКЛАР КОЛОННАСЫ ТӨЗҮГӘ

Норлат районы колхозларында танклар колоннасы төзү өчен средство туплау зур оешканлык белән дәвам итә. Алар соңгы көннәрдә. Дәүләт банкысының район бүлегенә тагын да 500 мең сумнан артык акча тапшырдылар.

«Красный партизан» артеле колхозчылары, колхозчы хатын кызлары барлык көчләре һәм средстволары белән фронтка ярдәм итү дәрте белән яналар. Алар соңгы көндә 200 мең сумнан артык акча керттеләр.

Колхозчы Илюхинаның ире фронтта фашистик юлбасарларга каршы рәхимсез көрәшә. Ә үзе ул һәрбер эштә алдынгылык күрсәтә. Иптәш Илюхина танклар колоннасы төзү өчен 4.500 сум акча тапшырды. 75 яшьлек Гайфулла бабай Заһидуллинның да дүрт улы фашистларга каршы сугыша. Карт булуына карамастан, Гайфулла бабай колхозның иң алдынгысы. Ул оборонабызның көчен ныгыту өчен 5 мең сум акча кертте.

НЫКЛЫ БАЗА НИГЕЗЕНДӘ

1941 нче елны «Светоч» фабрикасы уңышсыз тәгәлләде. 1942 нче ел өчен дә экономик база әзерләнмәгән иде. Шул сәбәпле яңа елның беренче ае искиткеч түбән күрсәткеч белән тәмамланды. Директор иптәш Гобәйдуллина «Светоч» фабрикасын менә шушындый хәлдә кабул итте. Ул фабрикага килү белән аның экономик хәле белән яхшылап танышты, алда торган бурычлар турында эшчеләр коллективы белән сөйләште һәм киңәште.

— Бөтенесе фронт өчен! Гигант заводлардагы икейөз процентчылар үзләре ясаган дәһшәтле коралларны фронтка багышлыйлар. Оста тегүчеләр җылы киемнәрне сугышчыларга атап тегәләр. Киң колхоз басуларында, кыр стахановчылары мул уңышның күпчелек өлешен героик Кызыл Армиягә озатырга ашыгалар. Уйлап карагыз, иптәшләр! Без январь аенда сугышчыга күпме конфект, пряник һәм башка төрле тәмле ашамлыклар бирә алдык соң? Айлык планның үтәлеше 18 процент кына бит,—диде ул.

Җитәкченең бу сүзләре фабрика коллективында эштә җаваплылык хисен уятты. Эшчеләр оешканрак рәвештә эшли башладылар. Фабриканы мондый хурлыклы өзеклектән чыгарырга тырыштылар. Яшь кенә кыз комсомолка Юсупова фабрикада икейөз процентчылар хәрәкәтенең инициаторы булды. Ул беренче буларак икейөз процентчылар сафына басты һәм үзенең бригадасындагы эшчеләрнең дә икейөз процентчы булуына иреште. Бу бригададан башкалар да үрнәк алдылар. Нәтиҗәдә фабрика март ае планын 133 процентка җиткереп үтәде. Моннан соңгы айларда да социалистик ярыш нәтиҗәләре сокландыргыч матур булдылар. Фабрика Бөтенсоюз социалистик ярышында Союз күләмендә 3 нче урынны алды. Бу вакытта инде планның үтәлеше 230 процент иде.

Кондитер изделиеләре җитештерүче предприятиеләрнең икенчесе — Микоян исемендәге фабрика. Үзендә барлык мөмкинлекләрнең булуына да карамастан, ул да 3 нче кварталның икенче аенда, планы 43 процентка гына үтәде. «Светоч» фабрикасын өзеклектән чыгару эшендә күп кенә тәҗрибә алган директор иптәш Гобәйдуллинага анда да эшне хәзерге шартлар таләп иткәнчә оештыру бурычы йөкләнде. Фабрикада кондитер изделиеләре җитештерү өчен база бар. Ассортиментларны арттыру, изделиеләрнең сыйфатын яхшырту өчен мөмкинлекләр бар. Җиһазлар да җитәрлек. Күптән түгел генә яңа цех—шоколад цехы эшли башлады. Ләкин август аена кадәр бер генә цехта да эш мактарлык түгел иде.

— Сәбәп нәрсәдә? Ни өчен болай начар эшлибез?—дип сорады директор цех начальникларыннан. Производство киңәшмәләрендә дә шушы сорауга җавап эзләнде.

— Хезмәт дисциплинасы начар. Кадрлар җитешми, аларның квалификацияләрен күтәрү турында кайгыртылмый.

— Социалистик ярыш договорларының үтәлеше тикшерелми. Стахановча эшләүчеләрнең эш тәҗрибәләрен уртаклашу оештырылмаган.

Менә шушы кимчелекләрне бетерү өчен күп кенә көч куярга, партия һәм комсомол оешмасы белән берлектә эшләргә кирәк иде. Иптәш Гобәйдуллина биредә дә эшне эшчеләр коллективын өйрәнүдән башлады. Ул һәркөнне иртән, сәгать 9 да, цех җитәкчеләре җыелышында көндәлек эшләрне ничек башкару чараларын билгеләгәннән соң, үзенең күбрәк вакытын цехларда уздырды. Бу хәл директорны эшчеләр коллективына якынайтты. Кайсы цехка, нинди эшләрдә ярдәм итәргә кирәклекне күрсәтте.

Производство киңәшмәләрендә эшчеләрнең активлыгы артты. Фабрикада мастерларның роле үсте. Эшчеләр дә җитезрәк эшләү, чималга, электроэнергиягә һәм ягулыкка экономия ясау өчен тырыша башладылар.

Производство активлыгы фабрика күләмендә планның үтәлешенә нык тәэсир итте. Сентябрьдә инде планның үтәлеше 116 процент булды. Аерым цехлардан пряник цехында үтәлеш 212 процентка җитте. Фабрика октябрь планын 133 процент, ә ноябрь планын инде 176 процент итеп үтәде. Моңа кадәр үзенең планын бер генә тапкыр да тутыра алмаган шоколад цехы октябрьга 108 процентка, ә ноябрьда инде аны ике өлеш арттырып үтәде һәм фабрика Союз күләмендәге ярышта 3 нче урынга чыкты.

Бу хәл эшчеләрне тагын да ныграк рухландырды. 1942 нче елның ике кварталы буенча өзеклектә килгән фабрика үзенең йөз кызыллыгын героик хезмәте белән аклады. Декабрьда валовой продукция чыгару планы айның беренче көннәрендә үк үтәлде. Хәзер инде фабрика социалистик ярыш нәтиҗәләре буенча Союз күләмендә алдынгы урыннарның берсенә кандидат булып тора.

1942 нче ел үтте. Бу ел кондитер фабрикаларының икесенә дә менә шундый яхшы уңышлар китерде. Алар хәзер икесе дә Союз күләмендә күренекле урында торалар.

Микоян исемендәге фабриканың 1943 нче ел өчен билгеләнгән перспективалары аның яңа елны Ватан сугышы таләп иткәнчә каршылавын күрсәтә. 1943 нче елда фабрика кондитер изделиеләрен шикәрсез дә эшли алачак. Онны шикәрләндерү, чөгендер ширбәтләре ясау фабриканың үзендә эшләнәчәк, бисквит цехы җиһазландырылачак. Бу цехның миче соңгы техника буенча эшләнеп ягулыкка 25—30 процент экономия ясалачак һәм көн саен 6—8 тонна күләмендә төрле сорттагы бисквит пешереп чыгарылачак. 1943 нче елда конфект эшләүне арттыру да күздә тотыла. Конфект җитештерү өчен кирәкле чимал башка төрле әйберләр белән алмаштыру исәбенә эшләнәчәк.

Һичшиксез, фабрика сугыш шартларында килеп чыккан кыенлыклар алдында туктап калмас. Яңа елда, яңа энергия белән эшләп, фронтны, илне кондитер изделиеләре белән тәэмин итәр.

М. НУРЕТДИНОВА.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

31 нче ДЕКАБРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

31 нче декабрьга каршы төндә безнең гаскәрләр Сталинградтан көньяктарак, Донның урта агымы районында һәм Үзәк фронтта элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинградның заводлар районында совет пехотасы отрядлары, артиллерия һәм минометлар ярдәме белән, алга баруларында дәвам иттеләр һәм үзләренең позицияләрен шактый яхшырттылар. Дошманның берничә ДЗОТ ы һәм бер ротага якын гитлерчылар юк ителде.

Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак безнең пехота отрядлары аерым участокларда сугыш хәрәкәтләре алып бардылар. Безнең частьлар 200 гә якын гитлерчыны юк иттеләр. Немецларның 4 танкысы зарарланды һәм яндырылды, 5 миномет батареясы юк ителде, пехота төялгән 4 автомашинасы җимертелде. Безнең сугышчылар 18 пулемет, 150 ләп винтовка һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

Безнең очучылар аэродромнарда немецларның 10 самолетын юк иттеләр һәм зарарладылар. Һава сугышларында дошманның 2 самолеты атып төшерелде.

* * *

Сталинградтан көньяктарак безнең гаскәрләр чигенүче дошманны куып баруларында дәвам иттеләр. Гитлерчыларның аерым отрядларының каршылык күрсәтергә маташулары һөҗүм итүче совет частьларының ударлары белән туктатылды. Котельниково шәһәрендә моннан элек әйтелгән трофейлардан тыш тагын танкка каршы ата торган 40 орудие, авиация бомбалары саклана торган бер зур склад, сүтеп куелган 8 самолет, 4 авыр танк, ягулык тутырылган цистерналар, берничә паровоз һәм хәрәкәт составы кулга төшерелде. Н-че часть, алга таба барып, халык яши торган бер пунктны алды һәм 23 орудие, 16 автомашина, 100 ат кулга төшерде. 700 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары плен алынды.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм күп кенә участокларда үзләре алган позицияләрне ныгыттылар. Н-че часть сугышчылары немецларны көчле рәвештә ныгытылган оборона узелыннан бәреп чыгардылар һәм 260 гитлерчыны кырып ташладылар. 85 кеше плен алынды. 12 орудие, 17 пулемет, 5 радиостанция һәм бер азык склады кулга төшерелде. Икенче бер участокта дошман пехотасы һәм танклары берничә тапкыр бик каты контратакалар ясадылар. Башта алар безнең подразделениеләрне бераз кысрыклый алганнар иде. Соңыннан совет сугышчылары дошманга флангтан удар ясап, аны тәртипсез рәвештә чигенергә мәҗбүр иттеләр. Сугыш кырында 200 дән артык дошман солдатларының үле гәүдәләре һәм немецларның яндырылган 4 танкысы калды.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр актив сугыш хәрәкәтләре алып баруны дәвам иттерделәр. Великие Луки районында совет частьлары дошманның берничә терәк пунктын алдылар һәм 300 немец солдатын һәм офицерларын кырып ташладылар.

Ржевтан көнбатыштагы районда бер участокта командиры иптәш Ларцев булган безнең подразделениеләргә немецлар ун тапкыр контратака ясадылар. Безнең сугышчылар гитлерчыларның барлык контратакаларын кире кайтардылар. Бу сугышларда 500 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары үтерелде, дошман бик күп техникасын һәм коралларын югалтты.

* * *

Нальчиктан көньяк-көнчыгыштарак Терек аркылы үтеп чыккан безнең частьлар флангтан удар ясап, дошманны алып ташладылар. Сугыш нәтиҗәсендә немецларның 120 солдаты һәм офицеры юк ителде. Пленныйлар алынды. 4 орудие, 7 пулемет, 4 миномет, бер радиостанция, 3 поход кухнясы һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Орел өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отрядның партизаннары дошманның 4 хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә 4 паровоз, гаскәрләр һәм техника төялгән 82 вагон җимерелгән. Бик күп немец солдатлары һәм офицерлары үлгән. Шул ук партизаннар отряды халык яши торган 3 пунктта дошман гарнизоннарына кинәт һөҗүм ясаган. 43 гитлерчы кырып ташланган һәм немецларның аерым ротасының штабы тар-мар ителгән. Совет патриотлары штаб документларын, 22 винтовка; күп кенә сугыш припаслары һәм азык кулга төшергәннәр.

* * *

Воронеж өлкәсенең хәзер азат ителгән Атамановский хуторында торучылар немец-фашист басып алучыларның ерткычлыклары турында акт төзеделәр. Актта болай диелгән: «Гитлерчы мародерлар колхозның һәм колхозчыларның милекләрен таладылар. Алар крестьяннарның терлекләрен, азыкларын, шулай ук өс-баш һәм аяк киемнәрен талап алдылар. Немецлар колхоздагы бөтен ашлыкны, 44 атны, 22 сыерны, 8 үгезне, 56 дуңгызны; 27 сарыкны талап алдылар, кошчылык фермасын туздырдылар. Гитлерчы бандитлар мәктәптәге партларны ваттылар һәм яндырдылар, ишекләрне һәм тәрәзәләрне җимерделәр, укыту кирәк-яракларын һәм мәктәп китепханәсен яндырдылар. Гитлерчы кабахәтләр Егор Половьяновны, Наталья Резникованы, яралы политрук Василий Кушнаревны һәм плен алынган 7 кызылармеецны атып үтерделәр. Кызылармеецларның исемнәрен белеп булмады. Халык гитлерчылар урдасына ләгънәт укый һәм үзен азат итүче Кызыл Армияне зур шатлык белән каршы алды». Актка хутор кешеләреннән Дмитрий Бурлакин, Степан Дубинин, Меланья Коростова һәм Ирина Бурлакиналар кул куйды.

31 нче ДЕКАБРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

31 нче декабрьда безнең гаскәрләр Сталинград районында, Үзәк фронтта һәм Донның урта агымы районында элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр.

Безнең гаскәрләр Обливская шәһәрен һәм тимер юл станциясен һәм район үзәкләреннән Нижне Чирскаяны, Приютноены алдылар.

30 нчы декабрьда Сталинград районында 11 транспорт самолеты юк ителде.

* * *

30 нчы декабрьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 10 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 20 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 10 сугыш припаслары складын һәм бер ягулык складын шартлаттылар, өч батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең частьлар һөҗүмне дәвам иттерделәр, алга киттеләр һәм берничә кварталны алдылар. 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Сталинградтан төньяк - көнбатыштарак моннан ике көн элек безнең частьлар алган биеклек районында бик каты сугышлар дәвам итте. Дошман танклары һәм пехотасы 8 тапкыр контратакага күчтеләр, ләкин һәр берендә дә совет сугышчыларының ударлары астында артка таба тәгәрәделәр. Безнең частьлар, дошманны хәлсезләндергәннән соң, гитлерчыларга контрударлар ясап, 40 ка якын окопны алдылар. Немецларның 600 гә якын солдатлары һәм офицерлары үтерелде, дошманның 33 танкысы сафтан чыгарылды. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

Безнең очучылар һава сугышларында дошманның 4 самолетын бәреп төшерделәр.

* * *

Сталинградтан көньяктарак безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, уңышлы рәвештә алга баруларында дәвам иттеләр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Сиротский һәм Ивановка районында совет сугышчылары 700 дән артык дошман солдатын һәм офицерын плен алдылар. 18 кыр орудиесе, 16 зенит орудиесе, 20 автомашина, 1.240 винтовка, күп кенә сугыш припаслары һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Н-че часть подразделениеләре, дошманны халык яши торган бер пункттан бәреп чыгарып, 16 орудие, 25 пулемет, 19 автомашина һәм әйберләр тутырылган 2 склад кулга төшерделәр. 240 немец солдаты һәм офицеры плен алынды.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм күп кенә участокларда моннан элек алган позицияләрен ныгыттылар. Дошманның бер терәк пункты өчен булган сугышларда безнең частьлар бер батальонга якын немец пехотасын кырып ташладылар һәм 120 гитлерчыны плен алдылар.

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр Обливская шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар, күп трофейлар, шул исәптән самолетлар төялгән бер эшелон кулга төшерделәр.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр, ә аерым участокларда үзләренең позицияләрен яхшырттылар. Великие Луки районында совет частьлары дошманның чолганып алынган гарнизонын юк итү буенча сугышлар алып бардылар.

Ржевтан көнбатыштагы районда безнең частьлар дошманны ныгытылган позицияләрдән бәреп чыгардылар. Сугыш кырында дошманның 300 дән артык үле гәүдәләре һәм яндырылган 2 танкысы калды. Бер самоход орудие һәм бер сугыш припаслары складына кулга төшерелде.

* * *

Нальчиктан көньяк-көнчыгыштарак безнең гаскәрләр үзләре алган позицияләрне ныгыттылар һәм көчләренең бер өлеше белән һөҗүм сугышлары алып бардылар. Дошманның бер терәк пункты районында бик каты сугышлар барды. Бу сугышларда 400 гә якын гитлерчы юк ителде. Безнең артиллерия уты белән дошманның 6 орудиесе сафтан чыгарылды, йөк төялгән 12 автомашинасы юк ителде һәм 2 сугыш припаслары склады шартлатылды.

* * *

Витебск өлкәсендә хәрәкәт итүче, Котовский исемендәге партизаннар отряды дошманның бер хәрби эшелонын һәлак итүне оештырган. Бер паровоз җимерелгән һәм сугыш припаслары төялгән 10 вагон шартлатылган. Витебск партизаннарының икенче бер отряды ике ай эчендә немецларның 21 эшелонын юлдан чыгарган. 21 паровоз, шулай ук дошман солдатлары, кораллар һәм техника төялгән 25 вагон юк ителгән һәм зарарланган. Җимерек вагоннар астында калып 300 дән артык гитлерчы һәлак булган.

* * *

Франциянең азат укчылары немец оккупантларга каршы актив хәрәкәтләр алып баралар. Укчыларның хәрәкәттәге отрядлары шоссе юлларында көрәш алып баралар. Париж-Невер трассасында хәрәкәт итүче Франция патриотлары ике атна эчендә 28 йөк автомобилен һәм җиңел автомобильләрне яндырганнар, 85 немец солдатын һәм офицерын кырганнар. Марсель якынында патриотлар зур бер сугыш припаслары складын шартлатканнар һәм бер ягулык складын яндырганнар.

Сталинградка килү юлларында безнең гаскәрләрнең 6 атналык һөҗүменең йомгаклары

(Ахыры. Башы 1, 2 нче битләрдә)

Шул ук вакыт эчендә безнең гаскәрләр немецларның 1.249 самолетын, 1.187 танкысын, 1.459 орудиесен, 755 минометын, 2.708 пулеметын, 5.135 автомашинасын һәм күп кенә башка төрле сугыш милекләрен юк иттеләр.

Дошманның Сталинград группировкасын тар-мар итү һәм чолгап алу буенча Кызыл Армиянең верховный баш командованиесе планын тормышка ашыру Көньяк-Көнбатыш фронт командующие генерал-полковник **Н. Ф. Ватутин,** Сталинград фронты командующие генерал-полковник **А. И. Еременко,** Дон фронты командующие генерал - лейтенант **К. К. Рокоссовский,** Воронеж фронты командующие генерал-лейтенант **Ф. И. Голиков** командалыгында, верховный баш командование ставкасы вәкилләреннән армия генералы **Г. К. Жуков,** генерал-полковник **А. М. Василевский,** артиллерия генерал-полковнигы **Н. Н. Вороновларның** гомуми җитәкчелегендә үткәрелде.

Сугышларда генерал - лейтенант **П. И. Батов,** генерал - лейтенант **В. И. Кузнецов,** генерал-лейтенант **Д. Д. Лелюшенко,** генерал-лейтенант **Р. Я. Малиновский,** генерал - лейтенант **М. М. Попов,** генерал-лейтенант **П. Л. Романенко,** генерал-майор **И. М. Чистяков,** генерал - майор **Ф. И. Толбухин,** генерал майор **Н. И. Труфанов,** генерал-лейтенант **Ф. М. Харитонов** гаскәрләре үзләрен аеруча күрсәттеләр.

Болардан тыш, сугышларда танк гаскәрләре генерал-лейтенанты **В. М. Баданов,** танк гаскәрләре генерал-лейтенанты **П. А. Ротмистров,** генерал-майор **И. Н. Руссиянов,** танк гаскәрләре генерал-майоры **В. Т. Вольский,** танк гаскәрләре генерал-майоры **П. П. Полубояров,** танк гаскәрләре генерал-майоры **П. П. Павлов,** танк гаскәрләре генерал-майоры **А. Г. Родин,** танк гаскәрләре генерал-майоры **В. В. Бутков,** танк гаскәрләре генерал майоры **Т. И. Танасчишин,** генерал - майор **М. В. Волков,** генерал-майор **К. В. Свиридов** командалыгындагы танк корпуслары һәм механикалаштырылган корпуслар үзләрен аеруча күрсәттеләр.

Сталинград янында совет гаскәрләренең уңышка ирешүенә авиация генерал - лейтенанты **С. А. Красовскийның,** авиация генерал-майоры **Т. Т. Хрюкинның,** авиация генерал-майоры **Л. Г. Руденконың** авиация берләшмәләре булышлык иттеләр. Алар верховный баш командование ставкасы вәкилләреннән авиация генерал-лейтенанты **А. А. Новиков** һәм авиация генерал-лейтенанты **Ф. Я. Фалалеевларның** гомуми җитәкчелегендә хәрәкәт иттеләр.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Зур драма театры. Бүген көндезге 12 сәгатьтә—„Күренми торган ханым“, 7 сәгать 30 минутта—„Рус кешеләре“, 2 нче һәм 3 нче январьда кич—„Фронт“.

Яшь тамашачылар театры. Бүген көндезге 1 сәгатьтә—„Скосыревлар семьясы“ („Фронт“), кичке 7 сәгатьтә—„Мәзәкчеләр“.

„Электро“ — Художестволы яңа фильм—„Райком секретаре“.

„Пионер“ — көндез — „Дуслар“, кич—„Укытучы“.

„Унион“ — „Антон Иванович ачулана“.

„Чаткы“ — „Корыч ничек чыныкты“.

„Кызыл йолдыз“—„Тоткыннар“.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 4800 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ. № заказ 2986